**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«11» апреля 2022 № 124

Татарстан Республикасы
Әтнә районы Башкарма комитетының
юридик бүлеге турындагы нигезләмәне
раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елдагы № 131-ФЗ Федераль законның 34 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы, Татарстан Республикасы “Әтнә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, шулай ук Әтнә район Советының 19.11.2021 елдагы № 88 карары нигезендә Әтнә район башкарма комитеты структурасы үзгәрүгә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының юридик бүлеге турында кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар 01.01.2022 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

ТР Әтнә районы башкарма комитеты
җитәкчесенең 2022 ел
“11”апрелендәге 124 номерлы
карары белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ ЮРИДИК БҮЛЕГЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының юридик бүлеге Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының структур бүлекчәсе (алга таба - Бүлек) булып тора, юридик зат статусыннан башка;

1.2. Бүлек Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты эшчәнлеген хокукый тәэмин итү, шулай ук гамәлдәге закон кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өчен булдырылган;

1.3. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставы, муниципаль норматив хокукый актлар һәм әлеге Нигезләмәгә таяна;

1.4. Бүлек Татарстан Республикасының Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына;

1.5. Бүлек штаты Әтнә район башкарма комитетының штат расписаниесенә туры китереп туплана.

## 2. Бүлекнең төп функцияләре һәм бурычлары

Бүлекнең төп функцияләре һәм бурычлары:

2.1. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты эшчәнлеген хокукый тәэмин итү;

2.2. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне җайга сала торган боеру документларын камилләштерү, шулай ук Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенең норматив хокукый актлары һәм боеру документлары проектлары сыйфатын яхшырту максатларында эшне гамәлгә ашыру;

2.3. Җәмәгать судларында, гомуми юрисдикция судларында һәм арбитраж судларда, суд приставлары хезмәте бүлекчәләрендә Әтнә район башкарма комитеты мәнфәгатьләрен тәкъдим итү.

2.4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең территориаль органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты карамагындагы оешмалар һәм учреждениеләр белән күрсәтелгән органнарның хокукый эшчәнлеге өлкәсендә хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру.

## 3. Бүлек вәкаләтләре

Бүлек үз компетенциясе кысаларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе, шулай ук аның урынбасарларының норматив хокукый актлары һәм боеру документлары проектларын әзерләүдә катнаша;

3.2. Гражданнарның, оешмаларның хатларына җаваплар әзерләүдә, прокуратура органнары тәкъдимнәренә һәм протестларына; хокук саклау, контроль һәм башка күзәтчелек органнары тәкъдимнәренә җаваплар әзерләүдә катнаша;

3.3. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенең норматив-хокукый актларын һәм боеру документларын әзерләү тәҗрибәсен Әтнә район башкарма комитетының башка структур бүлекчәләре белән берлектә гомумиләштерә, аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны җитәкчегә карап тикшерүгә кертә;

3.4. Билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты мәнфәгатьләрен судларда һәм башка органнарда хокукый мәсьәләләрне карау өчен тәкъдим итә;

3.5. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты бүлекләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә үз компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча консультатив хокукый ярдәм күрсәтә;

3.6. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты килешүләренең гамәлдәге закон таләпләренә туры килүен тикшерә һәм аларны визалый;

3.7. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән комиссияләр эшендә, киңәшмәләрдә катнаша;

3.8. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән алар эшчәнлегенә хокукый ярдәм күрсәтү буенча хезмәттәшлек итә;

3.9. Гражданнарга хокукый белем бирүдә һәм белем бирү оешмалары укучыларын хокукый тәрбияләүдә катнаша;

3.10. Гамәлдәге законнар нигезендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

3.11. Бүлек эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүматларны, хисапларны тиешле органнарга җибәрә

3.12. Гамәлдәге законнар нигезендә башка вәкаләтләрне дә гамәлгә ашыра.

## 4. Бүлек эшчәнлеген оештыру

4.1. Бүлекне Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган башлык җитәкли;

4.2. Юридик бүлек башлыгы вазыйфасына конкурс нигезендә югары юридик белеме һәм муниципаль (дәүләт) хезмәтенең әйдәп баручы яки өлкән вазыйфаларында бер елдан да ким булмаган эш стажы яисә белгечлек буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы булган зат билгеләнә;

4.3. Бүлек башлыгы Бүлек эшчәнлеге белән бердәм идарә нигезендә җитәкчелек итә һәм Бүлеккә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен җавап тота;

4.4. Бүлек җитәкчесе Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның урынбасарлары тарафыннан законнарны куллану тәҗрибәсенә һәм хокукый эшнең башка юнәлешләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышканда үткәрелә торган киңәшмәләрдә катнаша;

4.5. Бүлек эшчәнлеген матди-техник, документаль һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының Әтнә районы башкарма комитеты тарафыннан башкарыла;

4.6. Бүлеккә хокукый эшкә карамый торган башка функцияләрне йөкләү рөхсәт ителми.

## 5. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

5.1 Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә гамәлгә ашырыла.